**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07.02.2019 № 138

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында җәмәгать тәртибен саклау турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, « Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү бердәм дәүләт системасы турында» 2003 елның 30 декабрендәге 794 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы территориясендә муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында җәмәгать тәртибен саклау турында Нигезләмәне раслау хакында” 2018 ел, 3 декабрь, 1075 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында җәмәгать тәртибен саклау максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Тарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында җәмәгать тәртибен саклау турында нигезләмәне расларга.
2. 2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Л.Н. Маняпов

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының

2019 ел, 7 февраль, 138 нче

карары белән расланды

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында җәмәгать тәртибен саклау турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында җәмәгать тәртибен саклау турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү бердәм дәүләт системасы турында» 2003 елның 30 декабрендәге 794 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 2004 елның 8 декабрендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында җәмәгать тәртибен саклау турындагы нигезләмәне раслау хакында»2018 елның 3 декабрендәге 1075 номерлы карары нигезендә эшләнде.

2. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында җәмәгать тәртибен саклауга юнәлдерелгән чаралар оештыруны билгели.

3. Гадәттән тыш хәлләр вакытында җәмәгать тәртибен саклау Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасының Нурлат звеносы эшчәнлеге кысаларында гамәлгә ашырыла.

4. Җәмәгать тәртибен саклауда төп чаралар булып:

массакүләм мәгълүмат чаралары аша гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы турында яки барлыкка килү турында, шулай ук хәбәр итүнең мобиль чараларын кулланып халыкка хәбәр итү;

гадәттән тыш хәлләр зонасында контроль-үткәрү режимын оештыру;

гадәттән тыш хәл зонасында транспортның барлык төрләре хәрәкәтен җайга салуны оештыру;

потенциаль куркыныч объектларны, яшәешне тәэмин итү объектларын, матди кыйммәтләрне һәм зыян күргән кешеләрнең шәхси милкен саклау;

гадәттән тыш хәлләр зонасында хокук бозуларны кисәтү һәм булдырмау;

гадәттән тыш хәл зонасына авария-коткару эшләрендә катнашмаган затларның үтеп керүен булдырмау өчен, әлеге урынны чолгап (урап, камап, аерып) алуны гамәлгә ашыру;

эвакуация чараларын үткәргәндә җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү;

паниканы, ялган һәм провокацион имеш-мимешләрне бетерү, шулай ук хокукка каршы гамәлләр очракларына чик кую;

югалган кешеләрне эзләү;

вафат булганнарның кемлеген ачыклау;

җәмәгать тәртибен саклау өчен җәлеп ителә торган көчләрнең һәм чараларның составын билгеләү һәм әзерләү, аларның гамәлләрен планлаштыру тора.

5. Гадәттән тыш хәлләрдә җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү бердәм дәүләт системасы турында» 2003 елның 30 декабрендәге 794 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә көч һәм чаралар җәлеп ителә.

6. Гадәттән тыш хәлләр вакытында җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү өчен көч һәм чаралар җәлеп итү Нурлат муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе карары белән гамәлгә ашырыла.

7. Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы Нурлат звеносы көчләре һәм чаралары гамәлләре белән идарә итү һәм координацияләү максатларында Нурлат муниципаль районы территориясендә муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында җәмәгать тәртибен саклауга юнәлдерелгән чараларны оештыруда катнашучы тиешле оператив штаб төзелә, ул шул исәптән гадәттән тыш хәл зонасында җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү буенча карарларны эшкәртә.

8. Нурлат муниципаль районы территориясендә муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында җәмәгать тәртибен саклауга юнәлдерелгән чараларны оештыруда катнашучы көчләр һәм чаралар белән гомуми җитәкчелек итүне Нурлат муниципаль районының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе гамәлгә ашыра.

9.Гадәттән тыш хәл зонасында җәмәгать тәртибен саклау, тәртип урнаштыручы төп көч һәм чаралар килеп җиткәнче гадәттән тыш хәл зонасына беренче булып килгән авария-коткару хезмәте (авария-коткару формированиесе) җитәкчесе тарафыннан оештырыла.

10. Гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча эшләрне җитәкләүченең карары, Россия Федерациясе законнары белән башка карар каралмаган очракта, гадәттән тыш хәл зонасында булган барлык гражданнар һәм оешмалар өчен мәҗбүри булып тора.

11. Нурлат муниципаль районы территориясендә муниципаль характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында җәмәгать тәртибен саклауга юнәлдерелгән чаралар үткәргәндә, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының территориаль органнары, Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләренең Татарстан Республикасы буенча көчләре һәм чаралары федераль законнарда билгеләнгән вәкаләтләр һәм бурычларга туры китереп кулланыла.